| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 25 марты № 4

«Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

9 статьяның 4 нче өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслау) чыганагы булып федераль бюджет акчалары (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш) торган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат формалаштыра;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы, Пионер урамы, 45 йорт - "Сатурн-Урал" ҖЧҖ, Киров ур., 3А йорт - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Киров ур., 4А йорт - мәдәният йорты бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Р.Гаделшина